ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14» июнь 2022 ел № 148

Әгерҗе муниципаль районында
җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен
төзүгә хокукны сату буенча
ачык аукцион уздыру турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә урнашкан җир ресурсларыннан нәтиҗәле файдалану максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11, 39.12 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Торак пунктларның җирләре составыннан җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокукны сату буенча аукцион үткәрергә һәм аукционга җир кишәрлекләре бирергә.

2.Аукцион комиссия составын расларга (1 нче кушымта).

3.Әгерҗе муниципаль районында аукционда җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокук сату өчен куела торган җир кишәрлекләренең исемлеген, бәяләү бәясе күләмен, сату өчен куела торган җир кишәрлегенең бәясен арттыру күләмен (аукцион адымын) расларга (2 нче кушымта).

4.Аукцион үткәрү һәм аның нәтиҗәләре турында мәгълүмати хәбәрне вакытлы матбугат басмасында - «Әгерҗе хәбәрләре» район газетасында бастырып чыгарырга, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.agryz.tatarstan.ru) һәм сатулар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең рәсми сайтында да (https://torgi.gov.ru) җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокукны сату буенча ачык аукцион уздыру турында хәбәр урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

5.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**Җитәкчесе** **А.Э.Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
14. 06. 2022 ел № 148
карарына 1 нче кушымта

**Аукцион комиссиясе составы**

1. Артур Элфатович Акбашев - комиссия рәисе, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;

2. Поносов Эдуард Александрович - комиссия рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе (килешү буенча);

**Комиссия әгъзалары:**

3. Лукшин Павел Алексеевич - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мөлкәти һәм җир мөнәсәбәтләре палаталарын тикшереп тору һәм исәпкә алу бүлеге башлыгы (килешү буенча);

4. Андреева Ирина Евгеньевна - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе урынбасары (килешү буенча);

5. Сәлимуллин Рафил Рәхимбай улы - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тәбәрле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетының
14.06 2022 ел № 148
карарына 2 нче кушымта

**Әгерҗе муниципаль районында аукционда җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсен төзүгә хокук сату өчен куела торган җир кишәрлекләренең исемлеген, бәяләү бәясе күләмен, сату өчен куела торган җир кишәрлегенең бәясен арттыру күләме (аукцион адымы)**

| № | Урнашу урыны, җир кишәрлегенең мәйданы, кадастр номеры, аукцион үткәрү өчен нигез, капиталь төзелеш объектының максималь һәм (яки) рөхсәт ителгән минималь рөхсәт ителгән параметрлары, капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыруның (технологик тоташтыру) техник шартлары һәм аларның гамәлдә булу вакыты, тоташтыру (технологик тоташтыру)өчен түләү турында мәгълүмат | Рөхсәт ителгән кулланылыш | Аренда срогы | Еллык аренда түләвенең башлангыч күләме, сум. | Аукцион адымы (беренчел бәядән 3% ), сум | Беренчел кертем (20% беренчел бәядән), сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1 | Татарстан Республикасы, Әгерҗе муниципаль районы, Әгерҗе ш., Лесопильная ур., 29г, 837 кв.м. Кадастр номеры - 16:01:220209:249 | Склад мәйданнары | 5 ел | 42687 | 1280,61 | 8537,40 |